*1.Мәктәптә дә, өйдә дә*
*Күрше кызы Зилә дә*
*Һаман мине тиргиләр,*
*“Трай тибәсең”,-диләр.(Г.Морат)*

*2.И каен ла, җырлый белмим,*
*Көем чыкмый-көйләсәм.*
*-Колагына аю баскан,-*
*Дип үрти мине Ләйсән.(Г.Морат)*

*3. Кыш үзен күрсәтә!*
*Күр, ничек гайрәт чәчә!*
*(Г.Хәсәнов)*

***Трай тибәсең***

***Колагына аю баскан***

***Гайрәт чәчә***

***Трай тибәсең- эшсез***

***Колагына аю баскан-көйсез***

***Гайрәт чәчә-дулый***

# ЧАГЫШТЫРЫГЫЗ:

1. Бакчада **кәкре каен** үсә.

2. Безнең бозауның **мөгезе чыкты** инде.

3. **Күз бәйләнгән** килеш уенчыкларны кисеп төшерергә кирәк иде.

1. Җитмәсә, әлеге адәм **кәкре каенга терәтеп** китте. (Ф. Х.)

2.Тотасың да үзенчә бер **мөгез чыгара** башлыйсың. (Ә. Ф.)

3.Мин урман авызына кергәндә **күз бәйләнеп** өлгергән иде инде. (Г. Б.)

**Күчерелмә мәгънәгә ия булган, таркалмый торган сүзтезмә –** фразеологик **әйтелмә дип атала.**

# ФРАЗЕОЛОГИК ӘЙТЕЛМӘЛӘР

# Максат

1) **белем бирү:** фразеологик әйтелмәләр турында төшенчә бирү; ирекле һәм тотрыклы сүзтезмәләр арасындагы аерманы билгеләү; татар һәм рус теле грамматикасын чагыштырырга өйрәтү; 2) **күнекмәләр булдыру:** фразеологизмнарны сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллана белү күнекмәсе формалаштыру; 3) **тәрбия бирү:** укучыларда дөрес сөйләм һәм әхлаклылык тәрбияләү; бердәм эшләү күнекмәләрен үстерү.

**Фразеологик әйтелмәләр ике яки берничә сүздән тора.**

Фразеологик әйтелмәләрне башка бер сүз белән алыштыру мөмкин.

# Мәсәлән:

- Кот очу – курку;
- Авыз еру – көлү;
- Кесәсе калын – бай;
- Карт төлке – хәйләкәр.

# Төрле телләрдә фразеологизмнар күп очракта охшаш булалар.

- Борын төбендә генә - под носом;
- Колагын торгызу – навострить уши;
- Бармак аша карау – смотреть сквозь пальцы.





# Эт белән мәче шикелле






- Араларыннан су да үтми.



- Борын салындыру



- Куллары алтын

# Алма төшәр урын юк






# Ял минуты




**Апрель**

Гөрләвекләр агалар,
Күктән кояш елмая.
Каңгылдашып, торналар
Тезелеп үтте бая.
Инешләрдә коена
Канатланып үрдәк, каз.
Җирне яшәртеп, безгэ
Гөлләр алып килә яз.

# *Урынын тап!*

Сүз кату

Сүз көрәштерү

Сүзен кисү

Сүз кайтару

Сүзсез калу

Сүзне үлчәп сөйләү

бәхәсләшү

эндәшү

җавап бирү

сүз төгәлләнмичә калу

Уйлап сөйләү

эндәшмәү

ТЕСТ

1. **Баш әйләнә** -

А) голова идет кругом;

Б) даю голову на отсечение;

В) ломать голову.

2. **Кулга кул тотынып** –

А) горит в руках;

Б) сидеть сложа руки;

В)рука об руку.

3. **Борын салындыру**-

А) задирать нос;

Б) вешать нос;

В) зарубить на носу.

4. **Авызына су капкан** –

А) воды не замутить;

Б) воды в рот набрал;

В) водой не разольешь.

5**. Йөрәк туктап калу** –

А) сердце не лежит;

Б) с легким сердцем;

В) сердце замирает.

6.**Уртак тел табу** –

а) распускать язык;

б) тянуть за язык;

в) найти общий язык

# Өйгә эш:

1. ***280 нче күнегү.”Тукай һәм Сәйдәш” текстыннан фразеологизмнарны сайлап алып язарга (мәҗбүри).***

2. ***Г.Тукай шигырьләреннән 5 өзек язарга (ярым иҗади).*** ***3. Фразеологизмнарны кертеп, әкият язарга. (иҗади)***

# Афәрин, булдырдыгыз!

